КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 июль г.Казань № 616

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы турында» 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар КабинетыКАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы турында» 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – ярдәм алучылар реестрын алып бару хакындагы һәм әлеге реестрлардан файдалануны технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү чараларына таләпләр хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 6 май, 358 нче карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – ярдәм алучылар реестрларын алып бару тәртибен һәм Әлеге реестрлардан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру чараларына карата таләпләрне раслау турында» 2017 ел, 31 май, 262 нче боерыгы» сүзләренә алыштырырга;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына:

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән берлектә, 60 көн эчендә Системаны булдыру буенча техник таләпләрне эшләргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасының (алга таба – шул ук эзлеклелектә 823 нче карар, ярдәмче программа) «Микрозаемнар бирү механизмнарын үстерү» чарасы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһаз лизингы шартнамәсе буенча беренче кертемне (авансны) түләү чыгымнарын субсидияләгәндә «Кече һәм урта эшмәкәрлекне, шул исәптән моноюнәлешле муниципаль берәмлекләрне үстерү буенча муниципаль программаларны (ярдәмче программаларны) тормышка ашыру кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелә торган ярдәм чараларын тормышка ашыру өчен Системаны эксплуатацияләүгә кертүне тәэмин итәргә;

2018 елда 823 нче карар белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасына караган «Җиһаз лизингын үстерү: кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары чыгымнарын субсидияләү («Лизинг-грант»)» һәм «Җиһаз сатып алу чыгымнарын субсидияләү» чаралары кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына күрсәтелә торган ярдәм чараларын тормышка ашыру өчен Системаны эксплуатацияләүгә кертүне тәэмин итәргә.»;

5 пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы турындагы нигезләмәдә:

1.1 нче пункта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – ярдәм алучылар реестрын алып бару хакындагы һәм әлеге реестрлардан файдалануны технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру ягыннан тәэмин итү чараларына таләпләр хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 ел, 6 май, 358 нче карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – ярдәм алучылар реестрларын алып бару тәртибен һәм Әлеге реестрлардан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру чараларына карата таләпләрне раслау турында» 2017 ел, 31 май, 262 нче боерыгы (алга таба – 262 нче боерык)» сүзләренә алыштырырга;

1.2 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чараларын күрсәткәндә документларны кабул итүнең һәм карап тикшерүнең бердәм стандарты (алга таба – Бердәм стандарт) – Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүгә вәкаләтле органнар һәм оешмалар

тарафыннан, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системасыннан файдаланып, бу карарның 4 нче пункты белән күздә тотылган чаралар кысаларында ярдәм алу өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тапшырган документларны кабул итү һәм карап тикшерү кагыйдәләрен билгели торган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган документ;»;

2.2 нче пунктның дүртенче абзацында «(ярдәм күрсәтүдән баш тарту)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. 262 нче боерык нигезендә ярдәм алучылар реестрына бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктындагы икенче, бишенче, сигезенче абзацларда, 2.2 нче пунктның дүртенче – алтынчы абзацларында, 2.3 нче пунктның бишенче, сигезенче абзацында, шулай ук «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 8 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктчасында каралган мәгълүматлар кертелә.»;

6.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Ярдәм алучылар реестрын алып бару Системаның функциональ операторы тарафыннан 262 нче боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

6.3 нче пунктта «358 нче карарның 8 нче пунктында» сүзләрен «бу Нигезләмәнең 2.4 нче пунктында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чараларын күрсәткәндә документларны кабул итүнең һәм карап тикшерүнең бердәм стандартында:

1.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеге мониторингы турында» 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карары) 4 нче пункты белән күздә тотылган чаралар кысаларында бу Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чараларын күрсәткәндә документларны кабул итүнең һәм карап тикшерүнең бердәм стандарты «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль закон нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүгә (алга таба – ярдәм) вәкаләтле органнар һәм оешмалар тарафыннан, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системасыннан файдаланып, ярдәм алу өчен кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тапшырган документларны кабул итү һәм карап тикшерү кагыйдәләрен билгели.»;

2.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 нче пункты нигезендә ярдәм чаралары күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге (мәгълүмат) ярдәм күрсәтү тәртибен раслый торган норматив хокукый актлар нигезендә билгеләнә.

Бердәм стандартның 2.1 пункты нигезендә алына торган документларны тапшыру (алу) ысуллары түбәндәге таблица мәгълүматларын исәпкә алып билгеләнә:

| Т/с | Документ (мәгълүмат) төре | Документны тапшыру (алу) формасы | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектының документ тапшыру (алу) ысулы | Ярдәм чарасы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Ярдәм чаралары күрсәтү турында гариза | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | ДХМХП аша яисә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча (кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты ихтыярына карап) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче – бишенче абзацлар нигезендә |
| 2. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты анкетасы | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | ДХМХП аша яисә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча (кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты ихтыярына карап) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 3. | Салым органыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектының Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче – бишенче абзацлар нигезендә |
| 4. | Федераль салым хезмәтеннән хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче һәм бишенче абзацлар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | урнашкан урын буенча | |
| 5. | Юридик затларның (индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестрыннан күчермә | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче – бишенче абзацлар нигезендә |
| 6. | Юридик затның агымдагы финанс елы өчен барлык дәрәҗәдәге бюджетларга фактта түләнгән салымнары суммасы турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенчау | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы бишенче абзац нигезендә |
| 7. | Күчемсез мөлкәт объектына милек хокукы (ия булу) турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 8. | Федераль салым хезмәтеннән гариза бирүченең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына каравы турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче – бишенче абзацлар нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | |
| 9. | Дәүләт ярдәме чараларын максатчан сарыф итүне раслый торган түләү документлары | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | ДХМХП аша яисә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча (кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты ихтыярына карап) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 10. | Оешманың банк исәпләре (депозитлары) турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 11. | Индивидуаль эшмәкәрнең банк исәпләре (депозитлары) турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 12. | Паспортның гамәлдә булуы турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганакта | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма документларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | |
| 13. | Транспорт чараларын теркәүгә алу гамәлләре һәм аларның хуҗалары турында мәгълүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганак-та | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма доку-ментларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты-ның 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 14. | Физик затларның ке-ремнәре турында мәгъ-лүматлар (2-НДФЛ белешмә кәгазьләре буенча) | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганак-та | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма доку-ментларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты-ның 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы өченче абзац нигезендә |
| 15. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реест-рыннан күчемсез мөлкәт объектлары һәм (яки) аларның хокук ияләре турында мәгъ-лүматлар | Электрон рәвештә яки кәгазь чыганак-та | Бу Бердәм стандартның 2.1 нче пункты нигезендә ярдәм күрсәтүче орган яки оешма доку-ментларны ВЭХТС аша ала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты шулай ук ярдәм күрсәтүче органга яки оешмага тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләрен тапшырырга хокуклы; ВЭХТС аша документларны алуга хокукый нигезләр булмаган очракта – ярдәм күрсәтүче орган яки оешма урнашкан урын буенча | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты-ның 2016 ел, 1 август, 530 нчы карарының 4 пунктындагы бишенче абзац нигезендә». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин